СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

22 ноябрь, 2023 ел Алабуга шәһәре № 292

Алабуга муниципаль районы Советының «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2022 елның 13 декабрендәге 216 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Алабуга муниципаль районындагы бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 83 һәм 86 статьяларына таянып, Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2022 елның 13 декабрендәге 216 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда

*1 өлештә*

1 пунктта «2 849 768,2» саннарын «2 943 263,6» саннарына алмаштырырга;

2 пунктта «3 061 912,4» саннарын «3 183 626,8» саннарына алмаштырырга;

3 пунктта «212 144,2» саннарын «240 363,2» саннарына алмаштырырга;

*3 өлештә*

1 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «2023 елга район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» яңа редакциядә бәян итәргә;

2) 3 статьяда

2 нче кушымтадагы 1 нче таблицаның «2023 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының фаразлана торган керемнәре күләме» үзгәрешләр кертелә торган өлешен бәян итәргә.

3) 5 статьяда:

3 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «2023 елга Алабуга муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» яңа редакциядә бәян итәргә;

4 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «2023 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча Алабуга муниципаль районы берәмлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә;

5 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «2023 елга муниципаль берәмлек бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Алабуга районы муниципаль берәмлегенең муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә;

4) 11 статьяда:

1 пунктта «380 621,3» саннарын «390 641,4» саннарына алмаштырырга;

10 нчы кушымтадагы 1 нче таблицаның «2022 елга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә муниципаль учреждениеләрне тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә җирлекләр бюджетларыннан район бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» үзгәрешләр кертелә торган өлешен бәян итәргә.

5) 13 статьяда:

11 нче кушымтадагы таблицаның «2023 елга өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар күләме» үзгәрешләр кертелә торган өлешен бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка һәм туризм мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

Рәис Р.М. Нуриев